СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

04.10.2024 г.Лениногорск № 76

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 17 декабрендәге 85 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында торглар үткәрмичә бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турындагы (03.03.2023 ел, №15 редакциядә) нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»03.08.2018 елгы 340-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында «Федераль законның 98 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елнын 25 декабрендәге 625-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы белән, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 17 декабрендәге 85 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында торглар үткәрмичә бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районында торглар үткәрмичә бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турында Нигезләмәгә 1 нче кушымтаның 4.2 пунктындагы 4.2.7 пунктчасында түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.7 җир кишәрлекләреннән файдаланганда шәһәр төзелеше регламентлары, төзелеш, экология, санитария-гигиена, янгынга каршы һәм башка кагыйдәләр, нормативлар таләпләрен үтәргә, җир кишәрлекләрендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләре нигезендә биналар, корылмалар төзүне, реконструкцияләүне гамәлгә ашырырга»;

б) 3 бүлектә «2022 һәм 2023 елларда» сүзләрен «2022, 2023 һәм 2024 елларда» сүзләренә алмаштырырга.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы “Лениногорск муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/)бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның «б» пункты рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2023 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы МКУга йөкләргә.

Лениногорск
муниципаль районы
Башлыгы урынбасары С.В.Тимаков